ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» ноября 2019 ел. № 460

**2020 елга Татарстан Республикасының “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законныц 99 статьясы, "Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

2020 елга Татарстан Республикасының “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтү коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3.Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
28 ноябрь 2019, 460
номерлы Карары белән

**2020 елга Татарстан Республикасының “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары**

| Юнәлеш | Территориаль дислокация | 1 укучыга бер елга норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм һәм туган якны өйрәнү | шәһәр | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | шәһәр | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль- икътисади | шәһәр | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл | 6 071 | 11 242 | 13 491 |